*Октябрь, 2020*

# Гимназия сулышы №1

***25 нче гимназия укучылары газетасы***

**Белем бәйрәме мизгелләре**



**Белем көне** - ул чәчәкләр һәм ак тасмалар бәйрәме. Бу көнне һәр укучы, чәчәк бәйләме тотып, уку йортына ашыга. Күпләр бу бәйрәмне **"Беренче кыңгырау"** бәйрәме дип тә йөртәләр, чөнки нәкъ менә бу көнне гимназия балалар бакчасыннан килгән "яңа" укучыларын каршы ала. Ап-ак тасма бәйләгән, кулларына кечкенә портфель тоткан укучылар беренче тапкыр белем йорты бусагасын атлап керә, беренче укытучылары белән очраша, беренче кыңгырау тавышын ишетә.

1нче сентябрь рәсми рәвештә "Белем көне" дип беренче тапкыр 1984нче елда игълан ителә. Бу көнне һәр укучы бәйрәм итә. Шулай да "Белем бәйрәме"н беренче сыйныфка баручылар аерым бер дулкынлану белән көтеп алалар



.



Быелгы беренчеләр -172.
Короновирус вәзгыяте аркасында бәйрәмдә гимназиянең беренче сыйныф укучылары һәм унберенче сыйныф укучылары, әти-әниләр катнашты. Гимназия директоры Гаранина Светлана Владимир кызы беренчеләрне бәйрәм белән котлады. Унберенчеләр балаларга тырышып укырга, кызыклы һәм мавыктыргыч белем алу юлында уңышлар теләделәр.
Беренче кыңгырауны 11 сыйныф укучысы Муллагалиев Айдар  һәм 1 А сыйныфы укучысы Мануйлова Амелия  яңгыратуга, беренче укытучылары белән балалар беренче дәрескә киттеләр. Рәхим итегез, кадерле укучылар!
Бакирова Алия

## 22 сентябрь-шәһәр көне

Түбән Кама чагыштырмача яшь шәһәр. Быел шәһәребезгә 54 яшь тулды. Шул уңайдан гимназиядә сыйныф сәгатьләре үткәрелде. Ә 10 А сыйныфта шәһәрнең 5нче номерлы китапханә хезмәткәрләре Нәвыйкова Л.М. һәм Мәгъсумова А.И. белән очрашу булып үтте.



Укучылар шәһәр тарихы турында күп мәгълүмат алдылар. Мәсәлән, китапханәчеләр алып килгән фотоальбомда, шәһәрнең 30-40 ел элек төшерелгән фотолардан үзләренә таныш булган урыннарны эзләделәр, кызыксындырган сорауларына җавап алдылар. Китапханәче Нәфыйкова Л.М. Татарстанның 100 еллык юбилеена багышланган иҗади эшләр бәйгесендә катнашучы Бакирова Алиягә, Хуҗҗәтов Адельгә Диплом тапшырды.Соңыннан бергәләп фотога төштеләр. Рәхимова Мария

## Планета – безнең уртак йортыбыз



21 октябрьдә 3 В сыйныфында Бөтенроссия экология дәресе үткәрелде. Дәресне гимназиянең «Өлкән сыйныфлар Советы» әгъзалары Ячменёва Анастасия, Грачёва Юлия, Хуҗҗәтов Адель үткәрде. Башлангыч сыйныф укучылары үз фатирларында суның каян килүен, күп санлы электр приборларын ничек саклык белән кулланырга, ни өчен чүпне аерым җыярга кирәклегенә төшенделәр.

Укучылар төркемнәргә бүленеп төрле эшлекле уеннарда катнаштылар. Мәсәлән, күп акча тотмыйча ничек фатирда ремонт ясау серләрен белделәр.

Һәркем үз йортында, фатирында суны,электр энергиясен саклап тотса, безне чолгап алган әйләнә-тирәне, табигатьне киләчәк буыннар өчен саклауга үзеннән өлеш кертәчәк.Садреева Эльмира

**Таныш булыгыз**



Титова Наталья Юрий кызы гимназиядә яңа уку елында эшли башлады. Ул математика һәм физика укытучысы: Казан федераль университетының Алабугадагы филиалында физика-математика факультетын тәмамлаган, 2017- 2020 елларда Олы Афанас урта мәктәбендә укытучы.




Мин Наталья Юрий кызына берничә сорау белән мөрәҗәгать иттем.
– Сыйныф житәкчесе булу авырмы?

- Бу сорауга җавап бирергә әле иртәрәк дип уйлыйм, чөнки сыйныф житәкчесе буларак күптән түгел эшли башладым. Сыйныфта 25 укучы. Минем өчен һәр укучым яңа, укылмаган китап кебек. Алар бик кызыксынучан, актив. Көн саен укучыларым турында күбрәк белергә тырышам. Бу яктан миңа укучыларымның беренче укытучылары Елина Татьяна Сергей кызы ярдәм итә. Сыйныф коллективының оешкан булуы, яңа килгән укучыларның сыйныфташлары белән уртак тел табуларында беренче укытучыларының өлеше зур дип уйлыйм.



-Сезгә гимназиядә эшләү ошыймы?

– Әйе, ошый. Коллегаларым ярдәмчел, нинди сорау белән мөрәҗәгать итсәм дә кире какмыйлар, ә укучыларга килсәк, алар белемгә омтылучан, талантлылар-музыка мәктәбенә, йөриләр, спорт белән шөгыльләнәләр, бию,рәсем түгәрәкләренә йөриләр.

- Наталья Юрьевна, сезгә эшегездә уңышлар телим. Бакирова Алия

**Татарча диктант**

26 сентябрьдә Бөтеньдөнья буенча «Татарча диктант» акциясе үткәрелде. Бу акция биш ел дәвамында «Татарстан республикасының дәүләт телләрен саклау һәм үстерү программасы»н тормышка ашыру максаты белән үткәрелә.




Гимназиядә татар теле буенча уз белемнәрен тикшереп карарга 50 дән артык кеше катнашты. Алар – гимназия укучылары, микрорайонда яшәүчеләр, әти-әниләр, укытучылар иде.

Диктанттагы билгене Татар-информ.татар сайтында «Билгем нинди?» бүлегендә белергә мөмкин. Потапова Екатерина

**Күзгә матурлык**

Кем ничектер, ә мин көз айларын яратам. Сентябрьнең ямьле кояшлы ял көнендә дусларым белән сөйләштек тә шәһәребезнең «Гаилә» паркына чыгып киттек.Парктагы ямьгә карап хозурландык. Алтын көзнең матур мизгелләрен фотога төшерәсебез килде.



Фотолар искиткеч килеп чыкты, Дусларым Диана һәм Анастасия белән паркның матурлыгына сокланып калырга ашыктык, чөнки көзнең «әбиләр чуагы

« дип йөртелгән матур көннәрен тиздән яңгырлы, моңсу, бертөрле көннәр алыштырачак. Кайбер фотоларны газета укучылары хөкеменә тәкъдим итәм. Баранкова Дана

**Яфрак бәйрәме**

Яңгыр түгел, кар да түгел,
Яфраклар ява җиргә.
Көз турында җырлыймын мин,
Кушыл син яңа җырга.
Сары, кызгылт, алтынсыман,
Агачның яфраклары,
Җил исә, ява яфрак, көзнең матур чаклары.

**Хөрмәтле укытучылар, һөнәри бәйрәмегез белән котлыйбыз!**

6 октябрь көнендә гимназия гөрләп торды. Балалар укытучыларына карата матур теләкләрен,  рәхмәт сүзләрен кызганмадылар.

Гимназиянең «Өлкән сыйныф укучылары» советы традиция буенча укытучылар көнендә дәресләр үткәрделәр.  Ә аларның остазлары хореография залында бию хәрәкәтләрен өйрәнделәр, артистлык осталыкларын шомарттылар һәм үзләренең интеллект дәрәҗәсен тикшерделәр.

Укучылар әзерләгән концерт бәйрәмнең кульминацион ноктасы булды. Гимназия укытучылары башкарган флешмоб һәркемгә ошады. Соңыннан барысы бергәләп истәлеккә фотога төштеләр.Шулай узды  гимназиядә үзидарә көне. Качаева Диана



**Кадерле укучыларыбыз!**

**«Гимназия сулышы» редакция коллективы сезне яңа уку елы башлану белән котлый. Сезгә белем үрләрен яулауда зур уңышлар, һәркайсыгызга нык сәламәтлек телибез. Әгәр сезнең безгә тәкъдим итәрлек яңалыкларыгыз булса хәбәрләрегезне 302001035@edu.tatar.ru электрон почтасына җибәрегез! Редактор Хуҗҗәтов Адель. Проект җитәкчесе Шарапова Н.Н.**